ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от « 07 » июня 2026 г. № 589

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының алмаштыручы гаиләләреннән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясен төзү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясенең «Опекада һәм попечительлектә торучы һәм тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә яшәүче балаларның хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2016 елның 19 маендагы 14-16 номерлы карарының 3.4 пункты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасының алмаштыручы гаиләләреннән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе турында» 2016 елның 26 июлендәге под-1437/16 номерлы боерыгы нигезендә, икенчел ятимлекне булдырмау һәм балаларны Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларына кайтару буенча кирәкле комплекслы чаралар күрү максатында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының алмаштыручы гаиләләреннән балаларны дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе төзергә (1 нче кушымта).

2. Алмаштыручы гаиләләрдән балаларны дәүләт оешмаларына кире кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турында Нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://www.arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Г.Шәймәрдановага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.А.Галимуллин

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Башкарма комитеты карарына**
**1 нче кушымта**
**«_07_» июль 2026 ел №_589_**

**Балаларны алмаштыручы гаиләләрдән дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. Шәймарданова Р. Г. | - | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, **эксперт комиссиясе рәисе** |
| 2. Яруллина Р.Г. | - | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе - **эксперт комиссиясе рәисе урынбасары** |
| 3.Шәрифуллина Г.Ф. | | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының опека һәм попечительлек буенча баш белгече - **эксперт комиссиясе секретаре** |

**Эксперт комиссиясе әгъзалары:**

| | | |
|---|---|---|
| 4.Муллахмәтов Н.Н. | - | Арча район башкарма комитетының “Мәгариф идарәсе” МКУ җитәкчесе; |
| 5. Сәмиева Н.Р. | - | Арча муниципаль районында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил; |
| 6.Габидуллина Г.З. | - | балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре; |
| 7.Һидиятуллина А.А. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре буенча төркеме өлкән инспекторы; |
| 8.Дәүләтшина Н.Р. | - | Арча муниципаль районында "ЦСОН" Мәрхәмәтлек үзәге" дәүләт автоном белем бирү учреждениесендә гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм бүлеге мөдире; |

9.Тәрбиягә алган ата-ана

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Башкарма комитеты карарына**
**2 нче кушымта**
**«07» июль 2026 ел №589**

## Балаларны алмаштыручы гаиләләрдән дәүләт оешмаларына кайтару очракларын анализлау буенча муниципаль эксперт комиссиясе турында нигезләмә

### 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасының алмаштыручы гаиләләреннән балаларны кире кайтару очракларын анализлау буенча эксперт комиссиясе (алга таба – комиссия) эшчәнлегенең тәртибен һәм оештыруын билгели.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

1.3. Комиссиянең составы һәм саны куелган бурычларны комплекслы хәл итү кирәклегеннән чыгып билгеләнә.

1.4. Комиссия үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы; ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт учреждениеләре; ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның гаиләгә урнашуына ярдәм итү, алмаштыручы гаиләләрне әзерләү һәм озатып йөрү үзәкләре; опека һәм попечительлек органнары; дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары; массакүләм мәгълүмат чаралары; иҗтимагый оешмалар белән берлектә гамәлгә ашыра.

1.5. Үз эшчәнлегендә муниципаль эксперт комиссиясе Россия Федерациясе Конституциясенә һәм законнарына, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе Указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

### 2.Эксперт комиссиясенең максатлары һәм бурычлары

2.1 Максат:

Балаларны алмаштыручы гаиләләрдән кире кайтару очракларының сәбәпләрен анализлау; кире кайтаруга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү; ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны дәүләт учреждениеләренә кире кайтару очракларында аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү.

2.2 Бурычлар:

2.2.1. Икенчел ятимлекне кисәтү, моңа китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү;

2.2.2. Балигъ булмаганнарны психологик-педагогик һәм социаль тернәкләндерү;

2.2.3. Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга карата булган рәхимсез мөгамәлә очракларын ачыклау һәм булдырмау.

## 3. Эксперт комиссиясе эшчәнлеген оештыру

Йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен комиссия әгъзалары:

3.1. Опека һәм попечительлек органнары, алмаштыручы гаиләләрне озата бару хезмәтләре эшен, алмаштыручы гаиләләрдән кире кайтаруларны профилактикалау буенча күрелгән чараларны өйрәнәләр һәм анализлыйлар;

3.2. Алмаштыручы гаиләләрдә балигъ булмаганнарга карата профилактика системасы органнарының һәм учреждениеләренең индивидуаль профилактика эшен үткәрүен һәм аның булуын, җәлеп ителгән социаль юнәлешле иҗтимагый берләшмәләрнең, тәрбиягә бала алган профессиональ ата-аналарның, социаль хезмәтләрнең булуын анализлыйлар һәм системага салалар.

3.3. Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны дәүләт учреждениеләренә кайтаруны профилактикалауга юнәлдерелгән программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашалар;

3.4. Балигъ булмаганнарның хокукларын яклау, икенчел ятимлекне профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3.5. Методик ярдәм күрсәтәләр, икенчел ятимлекне профилактикалауның барлык субъектларын мәгълүмати тәэмин итәләр;

3.6. Ачыкланган хокук бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрәләр, күрсәтелгән мәгълүматны саклаганда һәм файдаланганда аның конфиденциальлеген тәэмин итәләр;

3.7. Икенчел ятимлекне профилактикалау системасының тиешле субъектларына ятим балалар һәм ата - ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт учреждениеләренә кире кайтуларны кисәтү эшен камилләштерү турында тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә тапшыралар;

3.8. Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

## 4. Комиссия составы

4.1. Комиссия составына комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

4.2. Комиссия әгъзалары булып социаль ятимлекне профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (аларның урынбасарлары), гаилә кору белән шөгыльләнүче хезмәтләр белгечләре, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, балигъ булмаган ятим балалар һәм ата-ана

тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар белән эшләү тәҗрибәсе булган гражданнар булырга мөмкин.

## 5. Комиссия рәисенең хокуклары һәм бурычлары

5.1. Комиссия рәисе, Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәп, комиссия эшен оештыру һәм хисап тапшыру өчен шәхсән җаваплы була;

5.2. Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

5.3. Комиссия утырышында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

5.4. Комиссия утырышында тавыш биргәндә хәлиткеч тавыш хокукына ия;

5.5. Комиссияне дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда тәкъдим итә;

5.6. Комиссия утырышы көн тәртибен раслый;

5.7. Комиссия утырышы датасын билгели;

5.8. Комиссия әгъзаларына Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча үтәлергә тиешле мәҗбүри йөкләмәләр бирә;

5.9. Вәкаләтле органнарга (вазыйфаи затларга) комиссиянең персональ составын төзү буенча тәкъдимнәр тапшыра;

5.10. Комиссиянең эш планы үтәлешен тикшереп тора, комиссия карарларына имза сала;

5.11. Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт учреждениеләренә балаларның кире кайтуын кисәтүне профилактикалау эше турында билгеләнгән хисап бирүне тәэмин итә.

## 6. Комиссия әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

6.1. Комиссия әгъзалары Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне (эшләрне) караганда һәм тикшергәндә тигез хокукларга ия булалар;

6.2. Комиссия әгъзалары түбәндәге функцияләрне башкаралар::

6.2.1.Комиссия утырышында һәм аны әзерләүдә катнашалар;

6.2.2.Алдан (комиссия утырышына кадәр) аның каравына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән танышалар;

6.2.3.Мәсьәләне (эшне) карауны кичектереп тору һәм аның буенча өстәмә материаллар соратып алу турында тәкъдимнәр кертәләр;

6.2.4.Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт учреждениеләренә балаларны кире кайтаруны кисәтү, әлеге фактка китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү буенча эшне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертәләр;

6.2.5.Карала торган мәсьәләләр буенча комиссия кабул итә торган карарлар кабул итүдә катнашалар;

6.2.6.Комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр.

## 7. Эксперт комиссиясе утырышларын уздыру тәртибе

7.1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен уздырыла;

7.2. Комиссия утырышында аның әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары аның утырышларында алмаштыру хокукыннан башка катнашалар;

7.3. Комиссия утырышында аның рәисе рәислек итә;

7.4. Комиссия утырышындагы карарлар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышлары белән кабул ителә;

7.5. Комиссия утырышы беркетмәсенә комиссия утырышында рәислек итүче һәм комиссия утырышы секретаре имза сала.

7.6. Беркетмәдә күрсәтелә::

комиссия исеме;

утырыш датасы;

утырышны үткәрү вакыты һәм урыны;

комиссиядә катнашучы әгъзалар турында белешмәләр;

утырышта катнашучы башка затлар турында белешмәләр;

көн тәртибе;

көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча чыгышларның эчтәлеге;

карала торган мәсьәлә буенча ачыкланган фактлар (алар булганда);

әлеге фактларны булдырмый калуга китерә торган ачыкланган сәбәпләр һәм шартлар турында белешмәләр (алар булганда);

карала торган мәсьәлә буенча кабул ителгән карар;

балаларны ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен дәүләт учреждениеләренә кайтаруга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар;

7.7. Комиссия материаллары комиссия әгъзаларына, профилактика системасы органнарына һәм учреждениеләренә, кызыксынучы башка затларга һәм оешмаларга җибәрелә.

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ПРОКУРАТУРА**
**АРСКОГО РАЙОНА**
Галактионова ул., 1, Арск, 422000

568577 148307

Руководителю исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан

Абдуллину Л.И.

07.07.2026 №01-01-2025/594-26-20920009

Уважаемый Ленар Ильсурович!

Сообщаю, что прокуратурой района рассмотрен представленный Вами проект постановления исполнительного комитета Арского района «О создании экспертной комиссии по анализу случаев возврата детей из замещающих семей Арского муниципального района Республики Татарстан».

Содержащиеся в проекте постановления нормы достаточны для достижения цели правового регулирования. Правила юридической техники соблюдены. Проект НПА не содержит коррупциогенных факторов. Нарушений требований федерального и республиканского законодательства не выявлено. Замечаний по рассмотренному проекту НПА не имеется.

Заместитель прокурора района

младший советник юстиции Р.Н. Юсупов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат 008741A1777EBD1E5D82E251E51F994DD4
Владелец **Юсупов Рамиль Наилович**
Действителен с 09.04.2026 по 03.07.2027

Прокуратура Арского района Республики Татарстан
№ 01-01-2025/594-26-20920009